**Татарстан Республикасы Сарман муниипаль районы Чукмарлы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керүче Нарат - Асты авылы халык җыены карары**

**№ 2** **14.11.2019**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге составына керүче Нарат - Асты авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2019 елның 14 ноябрендә «I нче группа инвалидлар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Чукмарлы авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 200 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Нарат Асты авылы урамына вак таш җәю (таш ташу);
- Нарат - Асты авылындагы юлларны кыш көне кардан чистарту;
- Нарат-Асты авылында мәдәни чаралар уздыру өчен бүләкләр алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май)

ӘЙЕ ЮК?».

мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 44 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 44 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 44 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге составына керүче Нарат - Асты авылында узган халык җыенын-уздырылган, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга
2. Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге составына керүче Нарат - Асты авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «I нче группа инвалидлар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан

кала, Чукмарлы авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 200 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Нарат Асты авылы урамына вак таш җәю (таш ташу);
- Нарат - Асты авылындагы юлларны кыш көне кардан чистарту;
- Нарат-Асты авылында мәдәни чаралар уздыру өчен бүләкләр алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май)

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Нарат - Асты авылы, Нарат Асты урамы, 21а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Хадиуллин